**Аңлатма язуы.**

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

-Россия Федерациясенең "Россия Федерациясендә белем бирү турында"гы Федераль Законы (№273, 29.12.2012);

-Россия Федерациясенең "Россия Федерациясе халык телләре турында" гы Законы (№1807-1, 12.03.2014);

-Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы (№68-ТРЗ 22.07.2013);

-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе "8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" нең 2018-2019нчы уку елына укыту планы;

-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе "8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" нең гомуми белем бирүнең төп укыту программасы.

Программа мәктәпнең гамәлдәге укыту планы буенча атнага 1 сәгать исәбеннән елга 34 сәгать итеп төзелде.

Эш программасын тормышка ашыру өчен, түбәндәге укыту-методик комплекты файдаланылды.

1. Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 сыйныфлар. – Казан Татарстан китап нәшрияты, 2018.
2. Дәреслек: Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов. Татар теле Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен). Казан , Татарстан китап нәшрияты, 2012

**Уку фәненә характеристика**

**Максат:**

-татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, шушы тел нормаларын саклап, татар телендә тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә аралаша-аңлаша белү күнекмәләрен камилләштерү.

**Бурычлар:**

- татар халкына хас булган рухи, әхлакый һәм мәдәни төшенчәләр турында мәгълүмат бирүне дәвам итү;
- укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү;
- тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;
- укучыларда җәмгыяви яктан җайлашу һәм сөйләм барышында аралашучыга уңай йогынты ясау осталыгын үстерү.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны.**

Федераль базис укыту планында каралганча, туган телне өйрәнүгә 11 нче сыйныфта атнасына 1 сәгать исәбеннән елга 34 сәгать бирелә, бу Татарстан Республикасының базис укыту планына туры килә. укучылар белән индивидуаль эшләр каралган.

Эш программасы МБОУ "8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" нең 2018/2019 нчы уку елына күрсәтелгән дәресләр санына яраклаштырылды. 11 нче сыйныфларның нигез программасында татар теле дәресләренә 34 сәгать вакыт каралган. Мәктәпнең уку планында татар теленә атнага 1 сәгать бирелү сәбәпле, эш программасында елга 34 дәрес алынды. Шуңа күрә теоретик материалны өйрәнүгә, контроль һәм язма эшләргә, бәйләнешле сөйләм үстерүгә бирелгән сәгатьләр саны кыскартып алынды.

**Укыту предметының эчтәлеге**

**Грамматика. (1сәгать).**

Грамматика. Грамматика турында төшенчә.

Татар теле грамматикасына нигез салган галимнәр, аларның төп хезмәтләре.

Грамматиканың бүлекләре, аларның өйрәнү объектлары һәм бер берсе белән бәйләнеше.

**Морфология. (16 сәгать).**

Сүз ясалышы һәм сүз төзелеше. Морфология. Түбән классларда үткәннәрне кабатлау. Сүзләрне төркемләү классификациясе. Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, фигыль, аваз ияртемнәре, предикатив сүзләр. Бәйләгеч сүз төркемнәре: теркәгечләр, бәйлекләр. Модаль сүз төркемнәре: кисәкчәләр, ымлыклар, модаль сүзләр. Сүз төркемнәре арасындагы бәйләнеш. Сүз төркемнәренә морфологик анализ.

**Синтаксис һәм пунктуация. (12 сәгать).**

Синтаксис. Әлеге өлкәдә эшләгән галимнәр һәм аларның хезмәтләре. Түбән классларда синтаксис һәм пунктуация буенча үткәннәрне кабатлау һәм ныгыту: синтаксисның төп берәмлекләре (сүз, сүзтезмә, җөмлә кисәкләре, җөмлә, текст); гади һәм кушма җөмләләрнең төрләре; гади җөмлә синтаксисы: ияртүле һәм тезүле бәйләнеш, сүзтезмә, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре; җөмләләрне төркемләү принциплары һәм аларның төрләре, сүз тәртибе; кушма җөмлә синтаксисы: мәгънәләре ягыннан кушма җөмләләрнең төрләре; тезмә кушма җөмлә һәм иярченле кушма җөмлә. Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.Гади һәм кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау.

**Стилистика һәм сөйләм культурасы. (3 сәгать).**

Текст турында төшенчә, аның төп билгеләре. Текстның темасы, төп фикере. Микротема. Текстта җөмләләрнең һәм аерым кисәкләрнең тоташу ысуллары. Кызыл юл, (абзац).Сөйләмнең функциональ-мәгънәви төрләре: тасвирлау, хикәяләү, фикерләү. Текст төзелеше. План һәм тезис төзү. Текстны темасы, төп фикере һәм төзелеше ягыннан тикшерү. Текстны мәгънәви кисәкләргә бүлү һәм план төзү. Бөтен нормаларны истә тотып, төрле стиль һәм жанрдагы текстларны төзү (эзлеклелек, төенләнеш, темага туры килү һ.б.). Телдән һәм язма сөйләмгә бәя бирү, төзәтү, план һәм тезис төзү. Текст синтаксисы: тезем, чит сөйләмле текст. Автор сөйләме һәм чит сөйләм. Туры һәм кыек сөйләм, катнаш сөйләмнең үзенчәлекләре.

**Кабатлау. (3 сәгать).**

**“Туган тел (татар теле)” укыту предметының тематик планы**

| **Программаның төп темалары/ бүлекләре** | **Сәгать саны** | **Агымдагы һәм арадаш контроль;** | **Контроль формасы** |
|---|---|---|---|
| **Грамматика.** | | - | - |
| Грамматика турында гомуми төшенчә. Грамматиканың бүлекләре. | **1** | - | - |
| **Морфология.** | **16** | | |
| Татар теленең сүз төркемнәре. Морфологик анализ. | | Тестлаштыру№1,грамматик биремле диктант №1, сочинение№1, изложение№1, | Тест; Диктант; Сочинение; Изложение. |
| **Синтаксис.** | **12** | | |
| Төп синтаксик берәмлекләр: сүз, сүзтезмә һәм җөмлә. Гади һәм катлаулы җөмлә синтаксисы. | | Изложение№2; Сочинение№2; | Изложение; Сочинение. |
| **Стилистика һәм сөйләм культурасы.** | **3** | | |
| Текст турында төшенчә, аның төп билгеләре. Туры һәм кыек сөйләм. | | Грамматик биремле диктант№2 | Диктант |
| **Кабатлау** | **3** | Тестлаштыру№2 | Тест |

| Барлыгы: | 34 | | |
|---|---|---|---|

**11 нче сыйныфның татар төркемнәре өчен киңәйтелгән календарь-тематик план**

| № | Б.с. | Дәрес темасы | Сәгать саны | Эчтәлек элементлары | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | План | Факт |
| **Грамматика – 1 сәгать** | | | | | | |
| **1.** | 1.1 | Грамматика турында төшенчә, аның бүлекләре. Татар теле грамматикасына нигез салган галимнәр, аларның төп хезмәтләре. | 1 | Грамматика, аның бүлекләре, аларның өйрәнү объекты һәм үзара бәйләнеше турында гомуми мәгълүмат. | 3.09 | |
| **Морфология – 16 сәгать** | | | | | | |
| **2.** | 2.1 | Тел белеменең морфология бүлеге Татар телендә сүз төркемнәре: мөстәкыйль, бәйләгеч, модаль сүз төркемнәре. | 1 | Сүзләрне төркемләү принциплары. Алдагы сыйныфларда үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. | 10.09<br>9 | |
| **3.** | 2.2 | **“Сүз төркемнәре” темасына тикшерү эше (тестлаштыру) №1** | 1 | Орфографик кагыйдәләр, тыныш билгеләре, гарәп-фарсы алынмаларының дөрес язылышы. | 17 | |
| **4.** | 2.3 | Мөстәкыйль сүз төркемнәренең морфологик билгеләре. Исемләшә торган сүз төркемнәре. | 1 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, фигыль һәм аваз ияртемнәре. | 24 | |
| **5.** | 2.4 | Исем, сыйфат,сан сүз төркемнәренең җөмләдәге функциясе. | 1 | Исем, сыйфат,сан сүз төркемнәренең җөмләдәге функциясе. | 1.10 | |
| **6** | 2.5 | Төрле төркемчәдәге алмашлыкларны сөйләмдә куллану. | 1 | Алмашлыклар. Аларның төркемчәләре. | 8.10 | |
| **7.** | 2.6 | **БСҮ “Сүз төркемнәре” темасына сочинение№1 “Китап – белем чишмәсе”.** | 1 | Сүз төркемнәре: мөстәкыйль, бәйләгеч, модаль сүз төркемнәре. | 15.10 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **8.** | 2.7 | Фигыль сүз төркеменең грамматик билгеләре. Аларны морфологик һәм синтаксик яктан тикшерү. | 1 | Фигыль сүз төркеме, төркемчәләре. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләргә морфологик һәм синтаксик анализ. | 22.10 | |
| **9.** | 2.8 | Хаталар өстендә эш. Рәвеш. | 1 | Язма эшләрне бергәләп тикшерү. Сочинение хаталары өстендә эш. Рәвеш төркемчәләре. | 29.10 | |
| **10.** | 2.9 | Аваз ияртемнәре һәм хәбәрлек сүзләр. Аларның лексик-грамматик билгеләре. | 1 | Аваз ияртемнәре һәм хәбәрлек сүзләр. Аларның лексик-грамматик билгеләре. | 12.11 | |
| **11.** | 2.10 | Сүз төркемнәрен ныгыту. | 1 | Сүз төркемнәрен кабатлау. Контроль эшләргә әзерлек. | 19.11 | |
| **12.** | **2.11** | **Б.С.Ү. Изложение№1 "Керәшә"** | 1 | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү һәм сөйләп карау. Караламага язу, акка күчерү. | 26.11 | |
| **13.** | **2.12** | Хаталар өстендә эшләү. Контроль эшкә әзерлек. | 1 | Җөмләләрне стиль ягыннан тикшерү, барлык төр хаталарны кагыйдәләр буенча төзәтү. | 3.12 | |
| **14.** | **2.13** | **Морфология темасы буенча грамматик биремле диктант №1 "Умарталыкта"** | 1 | Диктант язу, грамматик биремнәрне эшләү. | 10.12 | |
| **15.** | **2.14** | **Хаталар өстендә эшләү.** Бәйләгеч сүз төркемнәре. Теркәгеч һәм бәйлек, аларның телдәге функциясе. | 1 | Диктанттагы хаталарны төзәтү. Бәйләгеч сүз төркемнәре: бәйлекләр, бәйлек сүзләр һәм теркәгечләр. | 17.12 | |
| **16** | 2.15 | Модаль сүз төркемнәре: кисәкчә һәм ымлыкның сөйләмдә кулланылышы | | Модаль сүз төркемнәре: хәбәрлек сүзләр, кисәкчәләр, ымлыклар. | 24.12 | |
| **17** | 2.16 | Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау. Сүзләрне морфологик яктан тикшерү. | | Мөстәкыйль, бәйләгеч, модаль сүз төркемнәре. Сүзләргә морфологик анализ тәртибе. | 14.01 | |
| **Синтаксис – 12 сәгать** | | | | | | |
| **18** | **3.1** | Җөмлә. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. | 1 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше төрләре.<br>Сүзләрнең ияртүле бәйләнеше. | 21.01 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **19** | **3.2** | Сүзтезмә. | 1 | Җөмләләрне сүзтезмәләргә таркату, синоним сүзтезмәләр белән җөмләләр төзү, фразеологик сүзтезмәләрнең мәгънәләрен иреккле сүзтезмәләр б-н алыштыру | 28.01 | |
| **20.** | **3.3** | Гади җөмлә төрләре. | 1 | Җөмләне дөрес интонация белән уку күнегүләре эшләнә, җөмлә төрләре билгеләнә. Җыйнак җөмләләр җәенкеләндерелә. | 4.02 | |
| **21** | **3.4** | Кушма җөмлә синтаксисы. | 1 | Кушма җөмлә төрләрен искә төшерү күнегүләре эшләү. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрнең үзенчәлекләре турында аңлату, тактада һәм дәфтәрдә күнегүләр башкару. | 11.02 | |
| **22** | **3.5** | Иярченле к.ж.<br>Иярченле к. ж.-нең мәгънә ягыннан төрләре. | 1 | Таблицага таянып, иярченле к.ж.-гә билгеләмә искә төшерелә, синтаксик анализ ясала, күнегүләр эшләнә, төзелеш ягыннан и.к.ж.-нең төрләре билгеләнә.<br>Тактада һәм дәфтәрдә күнегүләр эшләү: баш һәм иярчен ж.-не табу, тулы синт. анализ ясау. | 18.02 | |
| **23** | **3.6** | **Б.С.Ү. Сочинение№2 “Иң кадерле кешем”** | 1 | Бирелгән тема буенча фикер алышу, сөйләп карау, караламага һәм чистага күчерү. | 25.02 | |
| **24** | **3.7** | Синтетик һәм аналитик и. к. җөмләләр. | 1 | Синтетик һәм аналитик и. к. җөмләләргә синтаксик анализ ясау, аңлатма бирә белү күнекмәләрен үстерү, тәрҗемә итү. Күнегүләр аша тыныш билгеләрен, анализ ясау юлларын камилләштерү. Тәрҗемә итү. | 4.03 | |
| **25** | **3.8** | Күп иярченле кушма җөмләләр. | 1 | Укытучы таблица аша теманы искә төшерергә булыша, күнегүләр эшләнә, берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмләләр тикшерелә. | 11.03 | |
| **26** | **3.9** | Катнаш кушма җөмләләр. | 1 | Тактада бирелгән җөмләләрне тикшереп, чагыштырма анализ ясатыла, катнаш кушма ж.-нең үзенчәлеге күрсәтелә, күнегүләр эшләнә. | 18.03 | |
| **27** | **3.10** | Күп тезмәле кушма җөмлә. | 1 | Катлаулы төзелмәнең үзенчәлекләрен аңлату, күнегүләр эшләп ныгыту. | 1.04 | |
| ***28*** | **3.11** | **Б.С.Ү. Изложение№2 “Пауза”** | **1** | Ике кат укыгач, план төзетү, сөйләтеп карау, язу. | 8 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 29 | 3.12 | **Хаталар өстендә эшләү.** | 1 | Хаталарны кагыйдәгә туры китереп төзәтү. | 15 | |
| **Стилистика һәм сөйләм культурасы – 2сәгать** | | | | | | |
| 30 | 4.1 | Стилистика һәм сөйләм культурасы | 1 | Укытучының аңлатуы: әдәби сөйләм стильләре, синонимия – стилистиканың нигезе, сөйләм үзенчәлекләре, күнегүләр эшләтү һәм ныгыту. | 22 | |
| 31 | 4.2 | **Синтаксис темасы буенча грамматик биремле диктант №2**<br><br>**“Яшь дусларга бер сүз”** | 1 | Бирелгән текстны язу.<br>Текст буенча грамматик биремнәр эшләү. | 29.04 | |
| **10-11 нче сыйныфларда үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау – 3 сәгать** | | | | | | |
| 32 | 5.1 | БСУ.Хаталар өстендә эшләү. | 1 | Хаталарны кагыйдәләр буенча төзәтү. | 6.05 | |
| 33 | 5.2 | Арадаш аттестация эше. (тестлаштыру) | 1 | Тест биремнәре. | 13.05 | |
| 34 | 5.3 | Барлык үтелгән материалны кабатлау. | 1 | | 20.05 | |

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**
“Фонетика, орфоэпия һәм графика” бүлекләре буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

-сүзләргә фонетик анализ ясый;
-татар теленең орфоэпик кагыйдәләрен саклап сөйләшүнең мөһимлеген аңлый;
-татар теленең орфоэпик сүзлегеннән, төрле белешмә чыганаклардан кирәкле мәгълүматны табып, аларны тиешле урында дөрес итеп кулланырга өйрәнә.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

-сәнгатьле укуның төп чараларын аеру;
-проза һәм поэзия жанрларына караган текстларны сәнгатьле итеп уку;
-мультимедия формасындагы орфоэпик сүзлек һәм белешмә материаллардан кирәкле мәгълүматны эзләп табып, аны үзенә кирәк вакытта файдалана белү.

“Морфемика һәм сүз төзелеше” бүлекләре буенча

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**

-сүзне морфемаларга бүлә;
-өйрәнелгән сүз ясалышы ысулларын билгели;
-бирелгән сүздән (тамырдан) төрле сүзләр ясый;
-морфемика һәм сүз ясалышын өйрәнү укучыны дөрес язарга, сүз төркемнәрен һәм җөмлә кисәкләрен танырга ярдәм итә.

**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**

-тамырдаш сүзләр арасындагы мәгънә бәйләнешен һәм чылбырын күрү;

-әдәби текстларда кулланылган сүз ясау элементларының сурәтләү чарасы буларак та әһәмиятен аңлау;
-сүз ясалуга караган сүзлекләр һәм белешмә материалдан (мультимедия чараларыннан) кирәкле мәгълүматны табу;
-сүзнең дөрес язылышын һәм лексик мәгънәсен аңлату өчен, аның этимологик ягына игътибар итү.
“Морфология” бүлеге буенча
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**
-татар телендәге сүз төркемнәрен аера белә;
-сүзләрне аерым сүз төркеменә керүе ягыннан (морфологик яктан) тикшерә;
-сүз төркемнәренең төрле формаларын хәзерге татар әдәби теле нормалары кысаларында куллана;
-морфологик белем һәм күнекмәләрне сүзләрнең дөрес язылышына, башка төрле анализларга бәйле рәвештә куллана.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**
-морфологиянең сүзлек составын тикшерү;
-грамматик омонимнарны аеру;
-публицистик һәм әдәби жанрдагы текстларда морфологик берәмлекләрне тану, фәнни һәм махсус эш стилендә кулланыла торган морфологик формаларны белү;
-төрле сүзлекләрдән һәм мультимедия чараларыннан морфологиягә кирәкле мәгълүматны эзләп табу.
“Синтаксис” бүлеге буенча
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**
-укучы синтаксисның төп берәмлекләреннән сүзтезмә һәм җөмләләрне, аларның төрләрен аерырга өйрәнә;
-сүзтезмә һәм җөмләләрне төзелеше һәм мәгънәләре, кулланылу үзенәлекләре ягыннан тикшерә;
-сүз төркемнәренең төрле формаларын хәзерге татар әдәби теле нормалары кысаларында куллана;
-укучылар синтаксистан булган белем һәм күнекмәләрен төрле ситуацияләрдә куллана белә.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**
-публицистик һәм әдәби жанрдагы текстларда синтаксик чараларны тану, фәнни һәм махсус эш стилендә кулланыла торган синтаксик чараларны белү;
-синтаксик конструкцияләрне функциональ-стилистик үзенчәлекләре ягыннан тикшерү, аларның сөйләмне сәнгатьле итү чарасы булуын аңлау.
“Стилистика” бүлеге буенча
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**
-функциональ (фәнни, рәсми эш һәм публицистик) стильләр белән таныша, аларның жанр үзенчәлекләрен билгели;
-аудитория (иптәшләре) алдында чыгыш ясарга өйрәнә: аның темасын билгели, максат һәм бурычларын күрсәтә;
-тел чараларын тыңлаучыларның яшь, психологик үзенчәлекләрен һәм сайланган теманың белем дәрәҗәсенә туры килүен һ.б. истә тотып сайлый.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**
-телдән һәм язма сөйләм арасындагы үзенчәлекләрне аңлау һәм аңлата белү;
-төрле стиль һәм жанрга караган текстлар белән эшләү (аларны билгеләнгән максаттан чыгып уку, мәгълүмати яктан кисәкләргә бүлеп эшкәртү);
-төрле характердагы текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү, бу вакытта телдән һәм язма сөйләм нормаларын саклап эш итү.
“Тел һәм мәдәният” бүлеге буенча
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнә:**
-милли-мәдәни компонентка ия булган тел берәмлекләрен халык авыз иҗаты әсәрләреннән, тарихи темаларга язылган һәм матур әдәбият әсәрләреннән аерып ала;

-телне өйрәнү ил тарихын һәм мәдәниятен яхшырак белергә ярдәм итә дигән фикерне раслардай мисаллар таба;
-көндәлек тормышта һәм укуда татар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен белеп тиешенчә куллана.
**Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:**
-телнең халык мәдәнияте һәм тарихы белән аерылгысыз бәйләнештә булуын аерым мисаллар ярдәмендә тасвирлау;
-татар сөйләм әдәбе кагыйдәләрен Россиядә яшәүче башка халыкларның сөйләм әдәбе кагыйдәләре белән чагыштыру, аларга характеристика бирү.

**Уку- укыту методик комплекты:**

Норматив һәм инструктив-методик материаллар;

1.Программа ”Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2018ел.

Укыту әсбабы:

1. Дәреслек: Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов. Татар теле Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен). Казан , Татарстан китап нәшрияты, 2012

Методик һәм дидактик материаллар:

1. Диктантлар җыентыгы: Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына . 5-11 нче с-флары өчен: Укытучылар өчен кулланма/З.Н.Хабибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина.-Казан: Мәгариф,2016.
2.Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы: “Рус мәктәпләрендә укучы татар балалары”на . 5-11 с-флары өчен Укытучылар өчен кулланма/Н.В.Максимов, С.М.Трофимова, М.З.Хамидуллина.-Казан:Мәгариф,2015
3.Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар.-Казан: Яңалиф, 2016
4.Бердәм республика имтиханына әзерләнү өчен ярдәмлек.Татар теле.-Казан: РИЦ “Школа”, 2008
6.Татар теленнән тестлар: Уку-укыту ярдәмлеге/Н.В.Максимов.-Казан: Мәгариф, 2018

Укытучы өчен әдәбият

1. Н.В. МаксимовТатар теленнән тестлар.2016
2. Р.Р. ШәмсетдиноваТатар теле. Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар2015
3. Ч.М. ХарисоваТатар теле. Теория. Күнегүләр. Тестлар2016
4. Ч.М. ХарисоваТатар теле. Анализ үрнәкләре2017
5. Н.Г. Гәрәева,Н.В. Максимов, Ә.Ә. Зыятдинова. Тел – белемнең ачкычы2015
6. Н.В. Максимов, З.В. Шәйхразиева. Урта мәктәптә татар теле укыту. Кушма җөмлә синтаксисы. 2015
7. Я.Х. Абдрәхимов. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре. 8-11 сыйныф. 2015

Укучылар өчен әдәбият.

1. Абдрәхимова Я.Х.. Татар теленнән мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр. 5-7 сыйныф. 2015.
2. Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр. 8-9 сыйныф.2015
3. Гәрәева Г.Х.. Татар теле. Уртаклашыр тәҗрибәм бар..2015
4. Максимов Н.В., С.М. Трофимова. Татар теленнән дидактик материаллар.8-11 сыйныф. 2015
5. Максимов Н.В., З.В. Шәйхразиева.Татар урта мәктәбендә синтаксик анализ.2017
6. Максимов Н.В., З.В. Шәйхразиева. Синтаксистан таблицалар һәм схемалар. 2017
7. Мәшһүр мәгърифәтче – галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту – тәрбия процессында файдалану. III кисәк.. 2017
8. Мәшһүр мәгърифәтче – галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту – тәрбия процессында файдалану. IV кисәк.2018

Интернет ресурслар:

- www.balarf.ru-“Бала” китапханәсе

- www.edu.tatar.ru --- электронное образование РТ
- http://mon.tatar.ru/ - министерство образования и науки РТ
- http://kitaphane.tatar.ru – национальная библиотека РТ
- http://shigriyat.ru– сайт для учителей татарского языка